ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерже шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» сентябрь 2020 ел № 311

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль
районының җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә
коммуналь инфраструктура объектларына карата
концессион килешүләр төзү һәм аларны тапшыру
буенча чаралар планын («Юл картасы») раслау турында

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы территориясендә концессия килешүләре шартларында муниципаль мөлкәттән файдалануга күчүне тәэмин итү максатларында, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы коммуналь инфраструктурасы объектларына карата җылылык белән тәэмин итү һәм аларны тапшыру өлкәсендә концессион килешүләр төзү буенча кушымтада бирелгән чаралар планын («Юл картасы») расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитытының
«22» сентябрь 2020 ел, № 311
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы коммуналь инфраструктурасы объектларына карата җылылык белән тәэмин итү һәм аларны тапшыру өлкәсендә концессион килешүләр төзү буенча кушымтада бирелгән чаралар планы («Юл картасы»)**

| № | Чараның атамасы | Башкару сроклары | Тормышка ашыру нәтиҗәләре | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Системаларны техник тикшерү турында хисап әзерләү, җылылык белән тәэмин итү схемаларын актуальләштерү | 20.09.2020 | Хисап, җылылык белән тәэмин итүнең актуаль схемасы | И.И. ӘМР башкарма комитеты җитәкчесе **И.И. Шәмсетдинов**, “Таткоммунэнерго” ААҖнең Әгерҗе участогы башлыгы **А.С. Авдеев** |
| 2 | КС төзү хокукына, конкурс комиссиясе составына, шул исәптән концессион килешү проектының тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты белән килештерүгә, карарларны, конкурс документациясен (алга таба - КД) әзерләү, килештерү, раслау. | 20.10.2020 | КС төзү, конкурс комиссиясе, концессион килешү проектын раслау турында МБ карары. | Әгерҗе муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе **Э.А. Поносов**, Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары **О.А. Баженова** |
| 3 | Конкурс документациясен һәм конкурс үткәрү турында хәбәрне рәсми бастырып чыгару | 23.10.2020 | МБ рәсми сайтында, МБ рәсми басмасында һәм рәсми www.torgi.gov.ru сайтында урнаштырылган хәбәр һәм КД | Конкурс комиссиясе |
| 4 | Конкурста катнашу өчен гаризалар кабул итү | 04.12.2020 | Теркәлгән гаризалар | Конкурс комиссиясе, потенциаль концессионерлар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Комиссия утырышлары, конкурста катнашучыларга хәбәрнамәләр җибәрү | 17.12.2020 | Конвертларны ачу беркетмәсе<br><br>Гаризаларны бәяләү беркетмәсе (беренчел сайлап алу)<br><br>Беркетмәләрне бастырып чыгару<br><br>Конкурс тәкъдимен кертү буенча тәкъдим белән хәбәрнамәләр җибәрелде | Конкурс комиссиясе |
| 6 | Конкурс тәкъдимнәрен кабул итү | 22.03.2021 | Теркәлгән конкурс тәкъдимнәре | Конкурс комиссиясе, потенциаль концессионерлар |
| 7 | Конкурс тәкъдимнәре салынган конвертларны ачу, конвертларны ачу беркетмәсе | 31.03.2021 | Конвертларны ачу, конкурсны үткәрү нәтиҗәләре турында беркетмә | Конкурс комиссиясе |
| *8* | *Конкурс узмады (2-дән кимрәк заявка)* | Конкурсны узмаган дип тану турында карар кабул ителгән көннән алып 30 көн | *Бердәнбер мөрәҗәгать итүче белән килешү төзү турында карар кабул итү* | *Конкурс комиссиясе* |
| 9 | Конкурс үткәрү нәтиҗәләре турында беркетмә бастырып чыгару һәм концессион килешү төзү | конкурс уздыру нәтиҗәләре турында беркетмәгә имза салынган көннән башлап 25 эш көне | Төзелгән КС | Концедент, концессионер, муниципаль берәмлек |